Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

# КАРАР №L-4

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 17 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, 2019 елның 16 декабрендәге “Россия Федерациясе Хезмәт кодексына хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны электрон рәвештә формалаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында” 439-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 22.07.2013 № XXVII-6, 14.08.2014 №XXXIX-3, 13.12.2014 XLII-8, 14.11.2015 №V-3, 23.04.2016 №X-8, 16.11.2016 №XIII-9, 29.05.2017 №XIX-9, 23.10.2017 №XXII-6, 24.07.2018 №XXXII-4, 19.11.2018 № XXXVI-5, 20.12.2018 №XXXVII-2, №XLI-11 01.04.2019, №XLIV-4 22.07.2019, №XLV-13 24.09.2019 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2.6.7. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.6.7. 2020 елның 1 октябренә кадәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркатибе) вазифасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре урта һөнәри белем булуны һәм муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эш стажына – тиңдәшле рәвештә кимендә ике ел яисә кимендә өч ел булуны күздә тота дип билгеләргә.

2020 елның 1 октябреннән соң әлеге Нигезләмәнең 2.6.3 пунктында каралган квалификация таләпләре авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркатибе) вазифасын биләү өчен 2020 елның 1 октябренә кадәр вазифага билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләргә карата кулланылмый.”

1.2) 2.6.8. пункт өлешендә “2019 елның 1 гыйнвары” сүзләрен “2022 елның 1 гыйнвары” сүзләре белән алмаштырырга.

1.3) 7.1 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә катнашырга, түбәндәге очраклардан гайре:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәри берлек оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәри берлек оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) белән яллаучы вәкиленнән Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәт нигезендә түләүсез нигездә идарә итүдә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) оештыручы (акционер, катнашучы) булып муниципаль берәмлек торган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен оешманы оештыручы вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган үзидарәлек хокукый актлары нигезендә түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар.”;

1.4) 7.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 17 пунктча белән тулыландырырга:

“17) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнү.”.

1.5) 19.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дисциплинар җәзаларны куллану һәм алу тәртибе, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән тәгаенләнә”;

1.6) 10.1.3. пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматны, хезмәт шартнамәсе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;”;

1.7) 14.4.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14.4.9. Әлеге Нигезләмәнең 8, 9 һәм 19.1 пунктларында каралган җәзалар муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупцион хокук бозуны кылу турында мәгълүмат кергән көннән алып муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча хезмәткә яраксыз, аның отпускта булу чорларын исәпкә алмыйча алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупцион хокук бозу кылынган көннән алып өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларга җинаять эше буенча производство вакыты кертелми.”;

1.8) 16.9 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2) хезмәт кенәгәсе күчермәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны, хезмәт шартнамәсе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш”.

1.9) 20.6.11 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4) хезмәт кенәгәсе күчермәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны, хезмәт шартнамәсе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов